
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ФЕВРАЛЬ * 2024 * КАЗАН

2

Александр ШУЛЬПИНОВ



Алмаз ХӘМЗИН

БУЛМАСКА ТИЕШЛЕ ТИЕШЛӘР

Үзгәрде мохит дөньяда –
Хәтта һава торышы.
Бер билгесез юнәлештә
Кешеләрнең тормышы.

Кышын хәзер яңгыр ява,
Су баса шәһәрләрне.
Артистлар да җүләрләнде,
Чишенеп шәрәләнде.

Җәен ут каба кырларга,
Яндыра авылларны.
Җир сөрергә кирәк булыр
Чакыртып маймылларны.

Яз җитүгә килә иде
Элек безгә әрмәннәр.
Хәзер басты үзбәк, таҗик –
Өнсез калды әрләннәр.

Качты илдән котсыз байлар,
Урлап соңгы тиенне.
Без җыябыз саклап илне,
Салып соңгы киемне.


Элек тә булгандыр инде
Ул гарип-горабалар.
Бүгенге күк алар рухсыз,
Ләкин бит булмаганнар!..

Акча җыя гади халык –
Кызгана мескеннәрне.
Үз хәлләре хәлсез хәлдә,
Төшенке күңелләре.

Иң начары бу да түгел,
Белегез – ваемсызлык!
Һәм дә каһәр бер вирус бар,
Ул да булса – комсызлык!

Хәтта илдән чыгып качкан
Әхлак дигән зур сыйфат.
Әллә инде югалган ул,
Әллә бөтенләй вафат.

Шуны күрә, белә торып
Ни уйлый депутатлар?
Күкәй салуны кимется
Инде хәтта тавыклар...



Валерий ТАРАСЕНКО



ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Шомбай ага! Инде күп еллар буе "Чаян"ны укып киләм һәм сезнең кыю бәяләрегезгә, үткен фикерләрегезгә сокланам. Минемчә, сез – халык зирәклеге һәм җор теллелеге гәүдәләнеше. Уңайсызрак булса да, сорау бирергә телим: сезгә хәзер ничә яшь?

Ф. ЙОСЫПОВА, пенсионер

бөгелмә

– Җавап итеп шуны әйтә алам. Мин әле балаларны курыкмыйча үзләрен генә урамга чыгарып җибәргән вакытларны хәтерлим. Ул чакта теләсә кайсы үтеп баручы абый-апа, "баланы кыерсыталар" дигән сүздән курыкмыйча, чамадан тыш шукланган малай-шалайны җиңелчә чәпәп тәрбияли ала иде, – диде могътәбәр Шомбай ага.

Рәшит МИНҺАҖ

ЭСТРАДА ТИРӘСЕНДӘ

(кыек атып туры тидерүләр)

Татарны да, башкортны да имә.
Абзыйларга ярый беләи: тимә!

• • •

Уртакулны күтәрер,
Бөекләрне төшерер.
Авызыңны чамалап ач:
Абзыкайлар өшкерер!

• • •

Актанышны мактап йөрде,
Сабаны хәзер мактый.
Шулай мактый-мактый торгач,
Күтәрелде бит шактый.

• • •

Дуамал ул, исәр, диләр,
Булмый җыр гына җырлап.
Ярарга тырышып кара!
Торма монда лыгырдап.

• • •

Татарда да атказанды,
Башкортта да ат алды.
Үзбәккә кагыласы бар:
Дөя аласы калды.

Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО



Пирамида корбаннары

Бездә финанс пирамидаларының эшчәнлеге турында ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Заманында бөтен илгә яманатлары чыккан беренче "фараон"нарның кара эшләре күп кенә диваннан тормыйча гына мул табыш алырга теләүче "инвестор"ларны ыштансыз калдырды. Ләкин бу өлкәдә беренче юл салучыларның уңышсыз тәҗрибәсе нишләптер игътибарсыз калды.

Бүгенге афера осталары Интернетта оялады. Алар ысулларын үзгәртсәләр дә, иске гадәтләренә тугры калдылар. Төрле "яшәргә өйрәтүче" курслар, инвестиция фондлары, бизнес-тренинглар азык тапкан тараканнар кебек үрчи. Әмма бу яңа шаукымнар тәэсиренә эләгүчеләр, гадәттә, бернинди табышсыз һәм муеннан бурычка батып кала. Ләкин шуңа да карамастан, үз теләге белән алданырга теләүчеләрнең саны һич кимеми.


«Пирамида зәхмәте» Татарстанны да читләтеп узмады, әлбәттә; зур уңышка өмет баглаучы "инвестор"лар монда җитәрлек – төп башына утыртырга өлгер генә. Соңгы ел эчендә генә хокук сакчылары биш эре финанс пирамидасының "көлен күккә очырды". Мәсәлән, акча салучыларга кеше ышанмаслык 365 процент вәгъдә иткән "Аметист" кооперативының "алтын кою осталары" ниһаять суд эскәмиясенә утырды. Алдау ысулы биш тиен бакыр кебек гади булып чыккан. Син алтын бизәнү әйберләре сатып аласың да аларны бер елга компаниядә сакланырга калдырасың. Мондый ышаныч өчен сертификат тоттыралар, салган акча әйләнешкә китә, ә сиңа көн саен процент тамып тора. Бу гамәл нәтиҗәсендә ике мең сертификат ияләренең берничәсе генә табыш алу бәхетенә ирешә, ә калганнарның акчалары, аңлашылганча, тиешле кешеләрнең кесәсенә күчеп утыра. Бу сумма 70 миллион сум тәшкил итә.

Тормыш күрсәткәнчә, алтында да күп акча эшләп булмый икән. Күптән түгел Чаллыда үтә зур табышлы "балык пирамидасы" корсагы белән өскә калкып чыга. Монда инде миллиардлар турында сүз бара. Җирле базарда ир белән хатын балык белән сәүдә иткәннәр. Берзаман алар эшмәкәрлекне киңәйтергә булганнар һәм гаилә бизнесына акча салучыларны тарта башлаганнар. Ул акчага диңгез продуктлары алып сатканнар, инвесторларга да процентлар тамызганнар. Эшләр шәп киткән, җиңел акча тәмен тойган халык хәтта машиналарын, фатирларын "залог"ка сала башлаган. Әмма бераздан болганчык суда балык үзен начар хис итә башлаган, ә балык пирамидасын оештыручылар хәзер суд карарын көтә.

Казанда яшәүче үткен хатын Илүсә башта телешоуда катнашып, күп эшләп, үзенә исем ясаган. Аннан соң инде исеме аңа эшли башлаган. Бу ханым, блогерга әверелеп, теләүчеләр өчен базар бәясеннән арзанрак бәягә Дубайга юлламалар тәкъдим итә башлаган. Ышаныч яулау өчен, ул арзан бәягә ял итәргә теләүчеләрнең беренче төркемен гарәб иленә җибәргән. Ә акча елга булып ага башлагач, үзе дә шунда юл тоткан һәм анда яшәп калган. Элемтәгә чыкмавына караганда, ул алданып калган йөзләрчә кешенең һич тә хәленә керергә теләми ахрысы.

Кеше кесәсеннән акча суырту сәнгате һаман нәфисләнә бара. Шуңа күрә тир түгеп җыйган акчаңны татлы тавышлы өндәүченең кулына тапшырганчы, башта яхшылап уйларга һәм җиңелчә булса да финанс һәм хокук мәсьәләләре белән танышып алырга кирәк. Хәтта сезнең янчыгыгыз бәрабәренә миллионер булып китәргә теләүчеләр дә башта законнарны өйрәнә, аннан соң гына аларны атлап чыгу ысулларын үзләштерә бит.

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр ШУЛЬПИНОВ

Сергей КОКАРЕВ



Вячеслав ШИЛОВ





Король йөрми, ә король йөреше бар.

Безнең авылны артка калдырып, медицина алга зур адымнар ясады.

Хакимияттәге туганнар – коррупция түгел, ә "гаилә хезмәт династиясе".

– Безнең институттагы иң нык таралган ике сүз нинди?

– Мин белмим...

– Әйе шул!

– Менә болай – минем фатирга күч, ашарга әзерлә, үзеңә эшләп алырга онытма һәм минем дорфалыкларга түзеп торырга күнек.

– Ә миңа болар нәрсәгә кирәк?

– Ярар, алайса башкачарак аңлатам. Кадерлем, мин сиңа ай белән йолдызларны бүләк итәм...

Хатын-кызның "5 минуттан әзер булам" дигәне белән ир-атның "5 минуттан өйгә кайтып җитәм" дигәне – бер үк нәрсә икәнен чамалаганыгыз булдымы?

Безнең илдә ике әйтем бергә яши: "Үзегезне дәвалау белән шөгыльләнмәгез" һәм терапевтка язылу – сентябрь аена".

– Сезнең бу эремчегегез бигрәк кыйммәт, әйтерсең сөттән эшләнгән...

Хәзер өч параллель чынбарлык яши: берсе – телевизорда, икенчесе – интернетта, өченчесе – чын тормышта.

Кешедә тәм, ис тою, күрү сәләтенең берсе юк икән, ул чакта аның калган барлык хисләре көчәя. Шуңа күрә юмор хисе булмаган кешеләрдә үзенең дәрәҗәсен күрсәтү хисе өстенлек ала.

Абау!

ТОТРЫКЛЫ КОРРУПЦИЯ

Тотрыклылык дигән нәрсә безнең тынгысыз заманда да яшәп килә икән. Татарстанда, мәсәлән, берничә ел инде коррупция бер дәрәҗәдә тора. Ел саен республикада меңләп ришвәтчелек очрагы теркәлә. Бу үтә яшәүчән күренештән котылыр өчен, һаман яңа юллар эзлиләр. Мисал өчен, ясалма интеллект мөмкинлекләрен киңрәк файдалану планлаштырыла. Ул ришвәтче зиһененнән зирәгрәк булыр дип уйлыйлардыр, күрәсең.

ЫШАНЫЧСЫЗ КӘНӘФИ

Лениногорск районы буенча ЮХИДИ башлыгы Айдар Хаҗиевны гадәти булмаган ришвәт алуда гаеплиләр. Бер машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән бәндә капитанга 11 мең сумлык офис кәнәфие бүләк иткән. Моның өчен ул район эчендә тоткарлаусыз рәвештә таныклыксыз йөрү мөмкинлеге сораган. Әмма башлыкка яңа кәнәфидә җәелеп утыру озак насыйп булмаган – яңа җиһазның каян килеп чыгуы белән кызыксына башлаганнар. Хәзер аңа башка, уңайсызрак урында утыру куркынычы яный.

КЫЮ ӨМЕТЛӘР


Фаразланган хезмәт хакы күләме буенча Казан алдынгылар сафына эләккән. Тикшерүләр буенча, казанлылар аена 122 мең сум алу өметләре белән дүртенче урынга чыкканнар. Иң кыю теләкләр Владивостокта яшәүчеләрдә булып чыккан – анда хезмәт хакының 127 мең сум булу турында хыялланалар. Аннан соң Волгоград һәм Рязань бара. Шунысы кызык: бу исемлеккә Мәскәү һәм Санкт-Петербург кермәгән. Аларның болай да барысы ал да гөл.

ГАРАЖ ХӘМЕРЕ

Кибет киштәләре төрле алкогольле эчемлекләрдән сыгылып торуга карамастан, ялган хәмер сөючеләрнең саны кимеми. Күптән түгел Казанда шундый эчемлекләр белән тулы гараж табылган. 1380 литр "продукция" шешәләргә тутырылып, сату өчен сәүдә челтәренә җибәрү өчен әзерләп куелган булган. Бу хәмернең составын һәм кеше организмына зарарын экспертиза билгеләячәк.

Михаил ЛАРИЧЕВ рәсемнәре





Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

БӘЙРӘМ БҮЛӘГЕ

Кич белән, йокларга җыена башлагач, хатыны сүз башлады:

– Карале, кадерлем, озакламый сезнең бәйрәм – 23 февраль җитә. Шуны уйлап йөрим көне-төне: сиңа нинди бүләк алып бирергә икән?

– Әй, нәрсә булса да ярый, анасы.

– Юк, син әйт.

– Соң, әйтсәм, аннары нинди бүләк була инде ул?

– Алай да, нәрсә теләр идең?

– Бик сорагач, әйтим инде.... Җәй көннәре балыкка йөрергә көймә алмакчы идем. Бераз акча да җыя башладым инде. Син бүләк итсәң, бигрәк шәп булыр.

– Көймә? Аннары ял саен балыкка барам дип, алдалап, өйдән качмассыңмы? Мин каян белергә тиеш, кая киткәнеңне? Әллә "сулга" киттең, әллә уңга... Юк, бераз гадирәк бүләк алам. Минем көймәлек акчам да юк.

– Ярар алайса. Эшебезгә бик әйбәт одеколон китергәннәр иде. Бәясе дә кыйбат түгел. Ә исе... исең китәрлек!..

– Ул хуш исле одеколон белән кемнәрне кызыктырмакчы буласың инде син? Яшь кызларнымы?

– Яхшы, анысы да кирәк түгел. Үзең уйла алайса. Миннән сорама, – дип, уфтанып җавап кайтарды ире.

– Беләм мин нәрсә бүләк итәргә. Ә менә син миңа 8 Мартка нәрсә бүләк итәрсең икән?


– Соң, син инде күптән уйланып йөрисең бугай. Йә алтын кибетенә, йә туннар кибетенә алып керерсең мине. Киеп караган буласың, көзге каршында боргаланасың... Ярар, размерларыңны беләм. Тик санарга кирәк, көймә акчасы җитәр микән...

– Әй сөеклем, бигрәк яратам да инде үзеңне!

Хатыны рәхәтләнеп йоклап китте.

"Ә миңа һәр елдагыча носки белән майка бүләк итәрсең инде..." дип уйлап куйды ире.

Виктор БОГОРАД



Равил МОСТАФИН



Җәй дә, кыш та ерак юлга
Чыккан кебек кешеләр.
Рюкзаклы җилкәләре –
Әйтерсең лә эшлеләр.

Юллары бит зур юл түгел,
Урам, базар, кибетләр.
Яңа мода – шуңа күпләр
Сәяхәтче кебекләр...

Күбесенең ыштан ертык:
Әйтәрсең алма баскан.
Койма өстеннән чыккан чакта
Ашыгып ертып качкан.

Егетләрнең өелгән чәч,
Нәкъ кызларныкы кебек:
Бантик кына куясы бар,
Йөргәч үзеннән көлеп!

Карый китсәң, саный китсәң,
Хәзерге чүп моданы.
Кызлары чәчен алдыра,
Акыл булгач чамалы.

Яшибез шундый заманда:
Кычкырыплар көләрлек.
Төрмә модасы яшьләрдә,
Монсы күпкә юләрлек.

Баштанаяк "тату" тулган,
Сылу, матур тәннәргә.
Утырып та торасы юк
ЗЭК булырга төрмәгә!..

Авыз, борын, колакларга
Тезелеп киткән боҗыра.
Үгез, сыер – әллә яшьләр,
Кычкырып сүк, йә җыла!

Бала карыннан чыгуга –
Чәче тутый кош төсле.
Исе дә китми беркемнең –
Һәркем үзенчә хисле!

Яши дөнья, ата таңнар,
Кояш нурларын сибә.
Әгәр шулай кирәк тапсаң,
Яшьләр күк яшә син дә.

Ямьләнерсең җәйләр кебек,
Яшәрер тәнең, йөзең.
Нәкъ яшьләрчә яши алсаң
Картаймассың һич үзең!

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

• Хәзер кыйммәтле машинаң булу синең бай булуыңны түгел, синең күпме тиеш икәнеңне күрсәтә.

• Руль артына утырасың икән – язмышның төрле борылышларына әзер бул.

• Кайбер машина йөртүчеләрдән: «Права сатып алгансың, ә «йөртергә өйрәнү»не сатып алмадыңмыни?» дип сорыйсы килә.

• Руль артына утыру белән, сары чәчле чибәркәй бер мизгелдә «буялган сарык»ка әйләнә.

• Халык сынамышы: әгәр юлны әле генә ремонтлаганнар икән, димәк, тиздән монда торбаларны алыштырачаклар.



Гомәр ВӘЛИЕВ

ЭЧКЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ

Күптән түгел бездә бик зур вакыйга булды. Зурдан кубып түләүле М-12 Мәскәү–Казан трассасын ачтылар. Кызыл тасма да киселде, яңа юл буйлап җилләтеп узгач, өскә рапорт та җибәрелде – җилдер генә! Әмма кузгалып китү белән машина йөртүчеләрнең башында уңайсыз сораулар туа башлады.

Мәсәлән, бездән җыелган бюджет акчасына төзелгән юл көтмәгәндә нигә түләүле булып китте? Бу сорауга ачык җавап, гадәттәгечә, булмады. Ә Казаннан Мәскәүгә вәгъдә ителгән алты сәгать ярым эчендә барып җиту белән ничек булырга? Чынлыкта бит бу юлга тугыз сәгать чамасы вакыт китә. Монда инде чираттагы сорау килеп туа: М-7 юлы буйлап шул ук вакыт эчендә бушлай барып булганда, М-12 юлыннан түләп йөрүнең мәгънәсе нидә соң?

Өстәвенә, яңа трассада запрвкаларда сәгатьләр буе чиратта торып интегү күренеше барлыкка килде. Моның сәбәбе бик гади: юлда заправка станцияләре җитми. Һәм тагын: "Автодор" белдерүенчә, "ике ай элек кенә ачылган станцияләренең коллективларында эчке мәсьәләләрне хәл итү процесслары тәмамланып җитмәгән". Ә бит ничек матур башланган иде, ул станцияләрне ничек мактаганнар иде…

Шунда ук ризасызлар өстенә файдалы киңәшләр ява башлады: трассага тулы бак белән чыгарга кирәк, заправка урынын алдан ук сайлап куярга кирәк, үз эшләрең белән китеп, автомобильне колонка янында калдырмаска, чиратны тоткарламаска. Һәм бөтен моң-зарлар белән АЗС хуҗаларына мөрәҗәгать итәргә.

Тик шулай да машина ияләренең сукранулары кирәкле урынга барып җиткән ахрысы – юл хуҗалары яңа заправка станцияләре ачу буенча эшләрне тизләтергә вәгъдә иткәннәр. Монысына да рәхмәт инде! Ә хәзергә безнең ишеләргә "бөке"ләрдә торасы гына кала – ә тиешле кешеләр эчке мәсьәләләрне хәл итүләрен дәвам итсеннәр.


• • •

Хәтәр җилдереп барган машинаны инспектор туктата. Рульдә – хатын-кыз.


Тәртип сакчысы кырыс кына:

– Ханым, сез нигә тизлекне арттырасыз? Штраф! – ди ул.

– Беләсезме, иптәш инспектор мин машинаны бик начар йөртәм. Берәрсен таптатмагаем дип өйгә ашыга идем.



Ринат АБЗАЛОВ







Сергей СУХОРУКОВ

Яраклы карар

– Утны сүндерегез әле!

Зал караңгылыкка чумды. Мин прожектор утыннан сукыраеп калгандай булдым. Сәхнәдән бернәрсә күрмим. Шулай булса да абруйлы комиссия әгъзаларының күзе миңа таба төшкәнен белеп торам.

Монысы инде мине соңгы сынавы иде. Музыка уйнап җибәрде һәм сулышымны көчкә җайлап җырлый башладым. Җырлавым белән әллә ни мактана алмыйм, шулай да хәйран әйбәт килеп чыкты бугай. Комиссия озак көттермәде.

– Юк! Шаляпин килеп чыкмый! – дигән тавыш ишетелде.

– Ул бит опера җырчысы түгел! – дипаклады мине икенчесе.

Миңа тагын бер куплет җырларга куштылар. Прожектор уты сәхнәнең рояль торган почмагына күчте. Уйный башладым, мине инде комиссия рәисенең тавышы бүлде:

– Ярый-й! Җитәр! Утны яктыртыгыз! Әйдәгез, коллегалар, нәтиҗә ясыйк.

Көчкә селкенеп, алагаем гәүдәле – чамалап булмаслык яшьтәге ханым күтәрелде.

– Төп фәннәрдән аның барлык билгеләре әйбәт, – дип мәгълүмат бирде ул. – Тик менә физкультурасы аксый, – дигән сүзен өстәп куйды. – Футболдан бигрәк тә. "Девятка"га туры китереп тибә белми.

– Малайлар өйрәтер! – дип өметләндерде ханымны спорт киемендәге ир-ат. – Мессидан ким уйнамас әле.

– Бәлки, – диде ханым. – Әмма кандидатка башка сораулар да бар. Рәхим итегез!

– Театр режиссеры буларак, – дигән сүзләр белән башлады берәү, – әйтеп утәм: образ тудыруы начар түгел, ә менә дикциясе коточкыч!

– Төзәтербез! – дип каршы төште комиссия рәисе. – Авызына таш тутырып сөйләргә өйрәтербез һәм телевидениедәге совет дикторлары кебек шомарыр! Гаеп табучылар бүтән юктыр бит?

– Ләкин бит ул Риман гипотезасын исбатлый алмады!!! – дип, ап-ак чәчле бер карт әтәч тавышлары чыгарып, каршы килеп маташты. – Ничек итеп аны эшкә кертәсең?!

– Аны инде ике йөз ел берәү дә исбатлый алмый, – дип, авызын томалады комиссия рәисе. – Менә ярты еллап өченче сыйныф мәсьәләләрен чишкәч – исбатлар! Шулай итеп, нәрсә эшлибез? – дигән сораулы караш ташлады ул барчасына.

Ай буе мине интектереп тикшергәннән соң, комиссия әгъзалары ризалык белдерде.

– Шулай итеп... – диде рәис, тантаналы төсмер биреп. – Тәбрик итәм, башлангыч сыйныфларда укытырга сез яраклы!!!



СӨЙЛӘГӘНЕГЕЗНЕ КҮЗӘТЕГЕЗ

Мәскәү Сәламәтлек саклау идарәсе табиб һәм пациент арасында әдәпле аралашу өчен тәкъдимнәрне хуплады. Хәзер кабул итү вакытында «Сәлам», «Сездә нәрсә?», «Әйе, кирәгез, мин тыңлыйм» дип әйтергә киңәш ителми. Аның урынына әдәпле сүзләр кулланырга кирәк: «Исәнмесез», «Сез үзегезне ничек хис итәсез?», «Сезне нәрсә борчый?» Бүлекнең тырышлыгы бушка китмәсен өчен, аудио язу җайланмалары ярдәмендә сөйләшүләрне күзәтәчәкләр. Мәгълүмат шәхси булмаячак, ләкин җыелышларда нәтиҗәләре конкрет булачак.

ТҮЛӘҮЛЕ ЮЛ

Мари Илендәге Алексеевское авылы кешеләре Мари Чодра милли паркы белән конфликтка кергәннәр. Көтмәгәндә авыл кешеләре озак еллар кулланган юл парк аша уза һәм аның саклану территориясенә кергәне ачыклана. Анда йөрергә ярый, тик түләүле, бер кешегә – 250 сум, ләкин хәзер машинада йөрү тыелган. «Хокук бозучылар» штрафка тартыла, машиналарын хәтта алып киткәннәр. Мари Иле һәм Россия Табигать ресурслары министрлыгы яңа бушлай юл төзү мәсьәләсен хәл иткәнче, халык ничектер юлы булмаган Эмеково авылы аша үз өйләренә әйләнеп кайтырга тиешләр.

СӘЯХӘТ ИТҮЧЕ МӘЙДАНЧЫК

Красноярск өлкәсенең Туруханский авыл советы башлыгы балаларны уен мәйданчыклары белән тәэмин итү проблемасын чишкән. 2014 елда авылның ерак районында төзелгән уен шәһәрчеге тылсымлы рәвештә авыл советы башлыгы яшәгән урынга күченгән, хәзер җирле балаларны сөендерә. Мәйданчыкны күчергән өчен, уен комплексларын ремонтлау өчен тиешле 400 мең сумны түләгән. Ачуы чыккан кешеләргә прокуратура булышкан. Алар башлыкка карусельләрне алган урынына кайтарырга һәм 20 мең сум штраф түләргә кушканнар.

ХАТЫН-КЫЗДАН ЭЗЛӘГЕЗ

Индонезиядә түрәләрнең югары коррупциягә бирелүләренең сәбәбен тапканнар. Бу күренештә политика һәм кеше хокуклары министры Мөхәммәт Мәхфуд ... дәүләт хезмәткәрләренең хатыннарын гаепләгән. «Күпчелек түрәләр хәзер төрмәдә, чөнки хатыннары алардан таләп итә һәм мөмкинлекләреннән яхшырак яши», диде сәясәтче. Министр сүзләре шунда ук хатын-кызларның ачуын чыгарган. Индонезиялеләр хатын-кызларны сарыф итүчеләр итеп күрсәтү искергән стереотип дип саныйлар.

Валентин ДУБИНИН



Сергей КОКАРЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Валерий ТАРАСЕНКО





• • •

Танылган язучы янына яшь табиб килә:

– Мин язучы булырга карар кылдым һәм шуңа күрә теңкәмә тиеп беткән медицинаны ташладым. Болай эшләвем белән кешеләргә күбрәк файда китерермен дип уйлыйм.

– Медицинаны ташлавыгыз белән генә дә сез кешеләргә инде зур файда китергәнсез...

Дамир МОРТАЗИН

Дәвалану ысуллары

Безнең авылдагы фельдшер кызны күптән оптимизләштерделәр, аптеканың булганы юк, ә ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәте язгы ташу вакытында һәм кышкы бураннарда бөтенләй туктый... Шуңа күрә югалган медицина хезмәтен бер Кузя бабай башкара. Ул – халык табибы, гасырлар буе тупланган тәҗрибәсен кулланып, һәр кешегә булышлык күрсәтә. Халык арасында аның булдыклылыгы инде бөтен тирә-якка таралган, рецептлары һәм дә дәвалау ысуллары бик гади, нәтиҗәле.

Мине дә ниндидер авыру эләктереп алды: әле бер җирдән кадый, әле икенче төштән чәнчи, күптән түгел менә аякларым йөрмәскә әйләнде. Берниндиі шикләнмичә Кузя бабайга юнәлттем аякларымны. Дәвалаучы әллә ни каршы тормыйча кабул итте.

– Утыр, хөрмәтлем! Салкыннан бер рюмка җиппәрү гөнаһ булмас. Мин аны үзем куам – дәвалау өчен. Күрешү уңаеннан! – дип, бабакай бер стаканны тозлаган кыяр кабып, каплап куйды. Мин – аның артыннан.

– Яхшы кеше икәнлегең әллә каян күренеп тора. Андыйларны дәвалау үзе бер рәхәт, – дип шатлыгын белдерде халык табибы. – Мин яхшы кешеләргә һәрвакыт ярдәм итәм, ә начарлары әнә врачларга барсын! – ди.

Мин аның фикерен куәтләп алдым, һәм без икенче мәртәбә салынганны капладык.

– Ярар, сөйлә әйдә, нәрсә борчый сине, яшәргә комачаулый? – дип сорады ниһаять хуҗа кеше өченче рюмканы соскач.

Мин аңа билдәге кадауларны әйттем. "Бу радикулит! Рецептын яз: бер стакан микстураны кара борыч белән болгатып, залп белән эчәргә. Момент тереләсең!"

Дикъкать белән рецептын яздым, безнең бабайларның борынгыдан килгән акыллы киңәшләре бит.

– Минем әле эчем дә авырта, – дип зарландым мин.

– Монысы ашказаны катары, – диде дәвалаучым. – Аны да төзәтербез! Аңа да бабайларыбыздан калган рецепт бар. Яз: стакан аласың, кызыл борыч – игътибарлы бул, кара борыч белән бутама! һәм бер сулыш белән эч. Онытма, залп белән, шулай итмәсәң, файдасы булмый!

Без тагын эчеп алдык бабай куганны һәм минем аякларга күчтек.

– Соң, синең бит, егет, подагра, – диде Кузя бабай һич шикләнмичә диагноз куеп, шундук дәвалау тактикасын билгеләде.

– Кул һәм аяк авыруларын медицина бик җиңел дәвалый. Яз рецептын: бер стакан минем эчемлеккә күңелең нинди борыч тели, шуны кушасың.

– Залп белән эчәргәме?

– Юк, подагра булганда – әкрен генә, кечкенә йотымлап. Йола да куя авыруны!

Шунда минем башыма бер уй килде: әгәр дә инде Кузя бабай теләсә нинди чирне дәвалый ала икән, нишләп әле ул минем иң төп авыруымнан котылырга булышмаска тиеш?

– Ә сезнең сәрхушлектән котылу өчен берәр рецепт юкмы? – дип сорарга булдым мин.

– Алкоголизмнанмы, – дип, фикеремә тәгаллек кертте халык дәвалаучысы. – Әлбәттә, бар. Яз: стакан, кара борыч, бер сулыш белән эчәсең...

– Залп беләнме?

– Әйе.

Сергей КОКАРЕВ



БӘДИГЫЙЗМНАР

• Карак ул – уңнан да, сулдан да карак дип укыла.

• Галстук тагып йөргәнгә, хәзерге ата каракларны тануы бик авыр.

• Әгәр урлашу спорт төренә керсә, безнекеләр гел Олимпия чемпионнары булыр иде.

• Энә урлап тотылмаган карак осталыгын дөя урлап тотылганга кадәр шомартып тора.

• Караклык җәмгыятьнең грим салынмаган чын йөзен чагылдыра.

• Рәшәткә артындагылар җәмгыятьнең үзен дә тимер ишекләр артына куып кертте.

• Карак читлектә дә урлар әйбер таба.

• Угрылар тәгәрмәч кебек: эресе – акрын, вагы тиз әйләнә.

• Урлашу Адәмнең рөхсәтсез алма ашавыннан ук башлана.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ

БАТТАЛИЗМНАР

• "Айлык пенсияң түзәрлекме?" дип сорамагыз. Түзәрлек! Соңгы егерме тугыз көне генә бик авыр уза...

• Аның ишегеннән чыкканда аягыгызны сөртергә онытмагыз!

• Без яшь чакта: "Минем хакта нәрсә уйлыйлар икән?" дип сагаябыз. Олыгайгач, нәрсә уйласалар да барыбер сыман. Картайгач ачыкланып бетә: безнең хакта бернәрсә дә уйламыйлар икән.

• Иксез-чиксез зур илдә яшәүнең файдасы да бар: качар урын күбрәк.

• Телевизор – кинотеатрлар каберлеге.

• Тешләреңне саклыйм дисәң... телеңне кыска тот.

• Уянган милләткә бишек җыры җырлаучылар күбәеп китте.


• Фәкыйрь илнең – гимны, начар тауарның рекламасы шәп була.

• Ходай хатын-кызны – ирләр өчен, ирләрне хатын-кызлар өчен оҗмах итеп яраткан. Ике арадагы тәмугны алар үзләре тудыра.

• Чыбык яшь чакта яхшырак бөгелә – дидек тә, яшь буынны бөкре итеп үстердек.

Фәнзаман БАТТАЛ

Максим СМАГИН



Виктор ФЁДОРОВ



Хәмид ВӘЛИДИ

СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК...

Барын беләм, бар ул Синдә
Бер сөйкемле сөягең.
Бу турыда үзең миңа
Кинәяләп сөйләдең.

Тик әйтмәдең, белгертмәдең,
Кай җиреңдә, читлектә.
Килә бер сыйпап куясым
Шул җиреңне ничек тә.

Тоям болай да тылсымын
Син янымда булганда.
Йөрим ни эшләргә белми,
Янымда булмаганда.

Юксынып шул сөягеңне
Сөякләрем сызлана.
Белә торып шул хәлемне
Ник белмисең кызгана?!

Синдәге сөйкемле сөяк,
Күрәсең, юктыр миндә,
Аның төсмере чагылыр
Иде лә күңелеңдә.

Сөйкемле сөяк ул синдә,
Бер генә түгелдер ул.
Кыйпылчыгын бүләк итче,
Үтенечем Сиңа шул.

Сәяси карикатура КОНКУРСЫ



Фарид ВАХИТОВ



Сергей КОКАРЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Иван ХАНТИМЕРОВ, 1971 ел

– Безнең цивилизациянең уты бу караңгы почмакта да нур сибә!



Виктор ИГНАТЬЕВ, 1969 ел

– Хәзер бу урамда тын булып калды!

Никифор ТУКМАЧЁВ

БАЛАЧАК

Безнең колхоз “Ленин юлы”
Исеме белән йөрде.
Авыздан өзеп дәүләткә
Икмәген, итен бирде.

Чит илгә бурыч түләде,
Читләми бирәүне дә.
Безгә ярап торыр, дидек,
Чикмәнле бәрәңге дә.

Дусларыбыз ач булмасын!
Ә дуслар – дөнья тулы.
Аларда да шул партия,
Анда да Ленин юлы.

Тайпылырга һич ярамый,
Партком кисәтеп тора.
Дөрес юлдан барабыз, дип,
Ленин күрсәтеп тора.

Туйганчы ашаган да юк,
Түлибез изге бурыч:
Муенда кызыл галстук,
Кулларда “үткен кылыч”.

Без бәхетле дип җырлыйбыз,
Хорга басып мәктәптә.
Бәхетнең нәрсә икәнен
Төштә дә күрмәсәк тә.

Аякта тишек чабата,
Өстә ямаулы кием.
Кырык налог түләтәләр,
Акча күргән юк тиен.

Оныта алсам бу көннәрне,
Язып та ятмас идем.
Балачакка юл булса да,
Мин кире кайтмас идем.

Гомер буе – икейөзлек,
Алдашу – гомер буе.
Әллә бу кыямәт көне,
Әллә бу шайтан туе.

Хәмид ВӘЛИДИ

ШАГЫЙРЬ ЯШЕНДӘ

Яшьлегемне искә төшерсәң дә,
Яшемне син искә төшермә.
Күңелемнең ак болытта чагы,
Иртә әле җиргә төшәргә.

Ак болытлар аша җиде күккә
Тургай сыман күңелем ашкына.
Һәр көнемне юрыйм хәерлегә
Туры килә юрау еш кына.

Җан дусларым белән теләктәшмен,
Ак теләк вә дога янәшә.
Берни түгел ара ераклыгы,
Җан сөйгәннәр сүзсез аңлаша.

– Ничә яшьтә? – диеп сорама син,
Мәхәббәтнең яше бармыни?!
Сөймәгәннәр генә тар, дип уйлый,
Сөйгән җанга Дөнья тармыни?!

Яшьлегемне искә төшерсәң дә,
Яшемне син искә төшермә.
Янып сөюемне кабул итсәң,
Яратуыңны да яшермә.

ИМӘННӘР...

Үз вазыйфасын имәннәр белә.
Имәннәр ята йорт нигезенә.
Шул имәннәр күк каһарман затлар
Ил нигезенә бер көн яталар.
Яшәрләр икән кемнәр бу илдә?
(Каһарман җанга анысы нигә?!
Үз вазыйфасын үтәде алар...)
Онытылмасыннар!
Илдә калганнар хәтерләсеннәр,
Ятсыннар тыныч каһарман җаннар.
Үсеннәр илдә гөрләп имәннәр!

Вячеслав ШИЛОВ рәсемнәре









• • •

Якутск шәһәренә бару билетының бәясе күпме икәнен белгәч, мин төгәл әйтә алам, Европага ни өчен ярлы кешеләр оча, Якутиягә – байлар.

• • •

Русларда бер мәкаль бар: "Знание и труд – всё перетрут!" Шуңа күрәдер инде хәзерге уку предметы итеп мәктәпкә "труд" дәресе керттеләр. Нәтиҗәсе – байтак укучылар мәктәпне с трудом тәмамлыйлар.

• • •

Яңа елда барлык авыл йортларында Интернет барлыкка киләчәк дип вәгъдә иттеләр. Шуның ярдәмендә кеше газ, кайнар су, җылылык һәм канализация булачагын беләчәк.

• • •

Хатыны уйлана:

– Кырынгычы бар, күбек чыгаргычы бар, ноские бар... Барысы да булганда, иргә бүләк алырга бигрәк авыр икән шул!

• • •

Доктор Хаус кебек даһи табиб булыр өчен белем һәм сарказм кирәк. Ә район дәваханәсендә аның сарказмы да җитә.

• • •

Авыру – докторга:

– Доктор, бәлки миңа операция ясамассыз – балаларым бар, хатыным...

– Ясыйбыз, ясыйбыз – минем дә гаиләмне туйдырасым бар!

• • •

Соңгы вакытларда дөньяви мәсьәләләр шулхәтле катлауланды, аларны чишәргә хәтта таксистлар да алынмый.

• • •

– Ничек яшисең?

– Башкалар ничек, мин дә шулай: яңалыкларны холодильниктан алам, ә ризыкны – телевизордан.



ЮЛ БАР – ХУҖАСЫ ЮК

Хөрмәтле редакция! Ныгытып уйласаң, караучысыз кешеләр һәм безнең якын дусларыбыз – йорт-җир хайваннары, алар гына түгел, юллар да була икән. Менә, мәсәлән, ике урам – Товарная һәм Торговая дип исемләнгәннәренә шәһәрне чыкканда "Казан шәһәре чиге" дигән билге куелган. Бу бит шәһәр бетте, шуның белән эш тә, мәшәкать тә юк дигән сүз түгел. Юл дәвам итә, ә Октябрь бистәсенә әле өч чакрым ара бар, аны берәү дә хәстәрләп карамый – хуҗасы юк. Җәен йөрү кыенлык тудырмый, инде кыш кергәч, менә шушы километрларны үтүгә авырлыклар барлыкка килә. Юл киңлеге чамадан тыш тарая, кар көрәлми, чистартылмый, катып бүлтәя, эретү реагентлары сибелми. Шуңа күрә шушы хуҗасыз – караусыз юлда һәрдаим аварияләр булып тора. Кемдер карарга, җыештырырга, җавап тотарга тиештер бит инде бу тәртипсезлекне?!.

А. ГАБИДУЛЛИН

КАЗАН

БЕР АЛДЫ, БЕР АРТЫ...

Кадерле "Чаян"! Тормыш кайчагында көтелмәгән шатлыклар да, кыенлыклар да тудыра. Бер алдын, бер артын күрсәтә, полоса-полоса – аклы-каралы була; елата да, көлдерә дә, диләр. Күңелгә ятышлысы азрак шул... Менә безнең бистәдә күңелсезрәге килеп чыкты бит әле.

"КЭМП" җәмәгать транспорты тукталышында берничә ел элек кешеләргә уңайлы булсын өчен, бигрәк тә физик мөмкинлекләре чикле булганнарга пандус куйдылар. Әлбәттә, бик кирәк нәрсә, ләкин нигәдер чыгышны юл ягына борып эшләделәр. Ярый әле юлның бу төшендә үзеннән-үзе калкып торган җире бар. Шуңа күрә машина йөртүчеләр тизлекне киметәләр, юлда бу өлеш яхшы күренә. Әмма күптән түгел генә ясалган ремонттан соң, бу бүлтәеп торган урын югалды, юл кырыенда тавыш томалаучы экраннар барлыкка килде, пандус өчен бераз ара калдырылды. Хәзер физик мөмкинлекләре чикләлеләр дә, машина йөртүчеләр дә гомерләре куркыныч хәлгә калулары ихтималдан сагаеп калды...

Залесный бистәсендә яшәүчеләр

КАЗАН

Бураннан буранга

Анастасия ВАСИЛЬЕВА




Александр АЛЁШИН



Александр ШУЛЬПИНОВ



Максим СМАГИН



Ринат АБЗАЛОВ



Алмаз ХӘМЗИН

БОЛАЙ ТҮГЕЛ ИДЕ ЭЛЕК

Без элек яшәгәндә болай түгел иде... Болай эшләми идек без... Авыр булса да, җайсыз, уңайсыз һәм каршылыклы, дәгъвалы хәлләрдә, мәсьәләләрдә үз фикеребезне белдереп-раслап, куәтләп гади эш кешесе өчен, халкыбыз йөзенә кызыллык китермәслек булсын дип эшләдек, гамәлләр кылдык. Нинди тармакта хезмәт итсәк тә максатыбыз бер булды – милләтебез рухына хилафлык төшермәү, бөеклеген күрсәтү һәм үстерү. Моны мин яшәвемнең бер мисалында тасвирламакчы булам.

Шулай: Татарстан телевидениесенда бик тә көчле вә мәртәбәле шәхесләр эшләгән вакытлар...

Яңа елда күрсәтеләчәк төп тапшыруны миңа йөкләделәр. Ягъни редакторы мин. Баш режиссерыбыз Әхтәм абый Зарипов, аның ярдәмчесе – Гасиман Ширгазин. Һәм башка бик мәгълүмнәрдән – Зәйтүн Яркәев, күренекле театр артистлары, данлыклы җырчыларыбыз – Илһам абыйлар, Әлфия апалар, музыкантларыбыз, гомумән, халкыбыз алдында шөһрәт казанган, сәнгатебездә зур урын тоткан шәхесләребез, авыл хуҗалыгы алдынгылары, производствода исемнәре Почет тактасыннан төшмәгән гади эшчеләр, күркәм укытучыларыбыз һәм башка бик күп намуслы мәшһүрләр!

Барлык бәйрәм кунакларының күкрәкләрендә лаеклы эш үрнәкләре өчен тагылган орден-медальләр студия прожекторы нурларында һәммәбезнең күңелен кытыклый – ягъни безне дә зур уңышларга өнди.

Берзаман студия кунаклары, үзләренең телевизорда күрсәтеләчәкләрен онытып, иркенәеп китәләр. Ә безгә шул гына кирәк. Шул бит инде чын бәйрәм. Шампан фужерлары чыңлый, артистлар җырлый, аларга зал кушыла, парлы биюләр башлана. Әнә, бер дә кыстатып тормыйча, Илһам Шакиров җырын сузып җибәрде:

"Йолдызлар сүнде, төн узган инде,
Бер йолдыз калды – ул Чулпан иде..."

Кара, Әлфия апа да янына чыгып, килештереп биегән була бит әле. Равил абый Шәрәфиев тә яшь кенә җырчы кызны әләктереп бии башлады – Зөһрә Шәрифуллина икән.

Үзем дә кызып киттем, Минтимер Шәрипович булып сөйли башладым – "Почему, патамушты – от части в части..." Әллә ни озакка сузмадым пародиямне, йә ошатмаслар дип тиз туктадым. Сәйдәш Гарифуллин белән Әнвәр Вәлиуллин башкаруында инструменталь әсәр башкаруга күчердем кичәне. Рояль кырыена шәм яндырып, өске япкычын ачып, ярыгыннан Сәйдәшнең фортепиано клавишаларында уйнавын күрсәтергә тотындык. Оператор егетебез ниләр генә кыланмый: фортепиано өсләренә ята-ята төшерә – шулай кирәк!.. Аларны кызыксындыру чарасын алдан күреп куйган идем шул. Мәйтәм: "Егетләр, үземә дигән сценарий акчасын сезгә бирермен", – дип. Эш анда да түгел, чынлыкта алар минем белән эшләргә бик яраталар иде. Чөнки телевидениедәге эшләгән һәр эшебез өчәр плюс белән "бишле" алып барды.

Йә, ярар, Шәймиевкә эшләгән пародияңә нәрсә диделәр соң, дип беләсегез киләдер?

Болай булды: без бу Яңа ел тапшыруының язмасын 31 декабрьдә көндезге сәгать уникегә монтажлап бетердек. Юри шулай иттек – ярамаган җирләрен сөрттермәсеннәр дип. Уникедән соң аны төзәтеп бетерә алмыйлар инде. Ничек монтировать ителгән, шул килеш күрсәтергә мәҗбүр булдылар.

...һәм шул ук төнне Сәкинә апабыз телевидение җитәкчеләренә шалтыратып болай дигән:

– Ай-яй, шәп тапшыру эшләгәнсез. Минтимер белән башыннан ахырына кадәр карап утырдык, рәхмәт сезгә! Бу эшкә кемнәр хезмәт куйган, аларга да рәхмәтебезне белдерегез! – дигән.

Менә шулай булган иде. Хәзерге Яңа ел кичен төшерүчеләр дә шундый рәхмәткә лаек булсыннар! Уңышлар телим.

Элек без эшләгәндә болай түгел иде, дип әйтмәслек булсын.

Безгә дә бәйрәм кирәк

Акчаны аз түлисез, дип,
Сатмагыз әле гайбәт.
Акча кешеләрне боза, –
Ә бездә халык әйбәт...

Рөстәм ЗАРИПОВ

Нинди генә бәйрәмнәр, нинди генә тантаналы көннәр юк безнең илдә... Әллә тагын көн саен... икешәр-өчәр булмаса... көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй!

Елның беренче көненнән атналап эшләмичә, ял итеп башлыйлар. Февральдә Ватанны саклаучылар көне туры килеп, җомга-шимбәдә өч көн түшәмгә төкереп яталар, аннан соң 8 Мартта шулай бәйрәм ясап, ашый-эчә күбенеп бетәләр. Күп тә үтми, Май ае башында ук Хезмәт бәйрәме уңаеннан өч көнгә якын һәм Җиңү көнен билгеләп, дәүләт эшеннән бизеп, сукранып йөриләр. Бакчасы булганнар ух-вах килә, билен турайта алмыйча яки аксый-туксый зардан арына алмый. Аннан соң Сабантуй бәйрәмнәре башлана. Кем кая тарала: берәүләр туган якларына кайта, икенчеләре дуслары янына кунакка бара. Көрәшәләр, ярышалар, уйныйлар, бииләр, җырлыйлар – кая монда печән әзерләү (хәер, хәзер авылда мал-туар асрамыйлар бугай), кышка утын турау-яру турында уйлыйсы да юк (һәр йортка газ кергән) – эш юк, ял итеп арыйсың, билләһи! Ә-ә, онытып җибәргәнмен, бәрәңге бакчасында колорадо коңгызын җыясы бар икән яки агу сиптерәсе. Ә-ә, ир-атлар балыкка баргалый, хатын-кызлар – җиләккә. Менә бәйрәм, менә җәннәт, менә хозурлык! Акчаң булса, ялга чык та, авылыңа кайт икән, күбрәк кучтәнәчләр алып, туганнарыңны сөендер. Инде бик баеп киткән булсаң, Төркиягә бар, Мисырда пирамидалар кара, Дубайга сыпырт, шунда торып кал! Байлар шулай итә бит хәзер, туган ягына сәлам дә бирми.

Нигә кереп киттем соң әле мин байларга бәйләнеп, алар өчен көн дә бәйрәм бит – ачу чыккандыр инде. Әнә дәүләт нихәтле бәйрәм ясаган халкына, шул җитмимени?.. Онытмаган берсен дә. Әле күптән түгел генә прокуратура хезмәткәрләре көне булып узды. Анысын бәйрәм итеп, бүләкләр алып, медаль-орденнар тагып бетерергә өлгермәделәр, следовательләрнеке килеп җитте. Анда да шулай тагулар, кул кысулар, ышаныч белдерүләр байтак ишетелде, күрелде. Полиция өчен дә бәйрәм үткәрелә, әйе, алар илдә тәртип саклыйлар. Гаишникларның да үз көннәре билгеләнгән – алар булмаса, юлларда нишләр идек?..

Армиядә хезмәт иткәннәрнең дә бар ул бәйрәме, аны әле солдат булмаганнар да бәйрәм итә. Шулай кирәк – Ватаныңны үзеңнеке иткәнчегә кадәрле сакларга, ярларга кирәк.

Шахтёрлар өчен дә бәйрәм бар, игенчеләр өчен дә, шофёрларга да, укытучыларга да, терлекчеләргә дә, химикларга да, физикларга да, академикларга да, космонавтларга да, журналистларга да, умартачыларга да, алкашларга да һәм башкаларга, һәм бүтәннәргә дә, әбиләргә дә, балаларга да, курчакларга да, искә алмаганнарга да, мәчеләргә, этләргә, бетләргә дә... Бөтенесенә бар. Әйе, алар илебезнең куәтен арттыруга үзләренең бөтен көчен куя, сәләтен җигә, җанын-тәнен бирә, гомерен кызганмый!

Тик менә, тик менә без – хәерчеләргә генә бәйрәм көне билгеләнмәгән. Хәерчеләр бәйрәме юк. Алар югыйсә илебез халкының иң күп өлешен тәшкил итә.

Инде бит ил байлыгын бүлешү эшенә дә тыгылмыйбыз. Хезмәт хакыбыз МРОТка да җитми. Зарланмыйбыз. Ил башлыкларының, министрларның, депутатларның нервасын да бозмыйбыз. Ашамыйбыз-эчмибез, киемнәребез дә элеккеге – совет заманыннан калган нык, сыйфатлы – тузмый торган. Яшебез дә пенсия яшеннән артып китте күпләребезнең – үлмибез. Хөкүмәткә мәшәкать ясыйсыбыз килми. Безгә инде бернәрсә дә кирәкми, бары тик бәйрәмебез булсын иде – "Хәерчеләр көне" дигән. Шауламый гына бәйрәм итәр идек. Салютлар аттырмый гына, вәгъдәләрен үтәүне сорамый, ялганнарына ышанган булып кыланып кына яшәр идек. Гафу – Ур-ра, кычкырырлык хәлебез инде калмаган.

ШӘМГУН





САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 2 (1939) февраль 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, РФ, РТ, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066 РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.02.2024 ел.
Тираж – 1001 Заказ А-0127
**Редакциянең адресы: 420066,
РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.**
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

Шагыйрә шәмсия …

Халык җыры "Онытылмас …" (И. Гази)

"… сулар, … сулар" "… трагедиясе"

Тимерханова "… каен" (З. Ярмәки)

Авто-мобиль

Шахмат фигурасы

9

4

"Беренче …" (Г. Камал)

Дәүләт

5

Инсан, шәхес

16 кг (-1)

3,14

"Көмеш тояк … атым"

Шатлык

"Ак чәчәк ата …"

Металл барометр

… күтәрү (спорт)

Әйткән сүз — аткан …

1

"Карлыгачлар … ясый"

Гыйбадәт (-2)…

"Сания … суга бара"

Казак офицеры



Ике урман арасы

Нота

"Иреннәре … гына"

Нота

Диңгез кысласы

"… сандугач микән"

2

Сәнгать төре



Жил- …

Нәсел, токым



Алманың якын туганы

8

"Минем атым уйнаганда кин болынннар була …!"

Чаян

Чиктән …

Планетаның формасы

"…-сок" (эпос)

"… зәйнәбем"

6

Ишекләр … көне

Базарда уртак фикер эзләү

"…" ана



"Уфа — чиләбе, пешә … җиләге"

"…" су

7

3

10

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Ничек итеп "менә дигән!" совет фильмын бозарга була?

2. Уңышсыз күрешү ничек була?

3. Бер минут көлү биш минутка гомерне озайта диләр, дөрес микән?

4. Дөньядагы иң куркыныч нәрсә?

5. Һиндстандагы һәм Рәсәйдәге кагылгысызлар нәрсәсе белән аерыла?

6. Мәрхәмәтлек кара була аламы?

7. Белая горячка. Нәрсә ул?

ҖАВАПЛАР

1. Хәзерге вакытта шуның дәвамын төшерү. 2. Кызга бер бәйләм чәчәк китереп, ә икенчесен алып китеп. 3. Кемнән көлүеңә карап... 4. Көнләшү (жаба). Җир йөзендәге халыкның яртысын диярлек җәфалый. 5. Һиндстанда алар – түбән катлам, ә бездә – югарыдагылар. 6. Әлбәттә. Бер банка кофе яки уылдык. 7. Дәртле блондинка.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 1 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«АНА САГЫШЫ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
З. ЗИННӘТУЛЛИНА (Апас),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас),

Җиңүчебез – Апастан


Зилә ЗИННӘТУЛЛИНА!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Виктор ФЁДОРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Валентин ДУБИНИН



Валерий ТАРАСЕНКО





